**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2017 ел, 24 апрель № 244

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибе турында» 2016 ел, 17 март, 148 нче карары белән расланган Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибенә кушымтага үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибе турында» 2016 ел, 17 март, 148 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 30 апрель, 271 нче, 2016 ел, 30 декабрь, 1061 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләр нигезендә) расланган Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибенә кушымтага, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә (теркәлгән).

2. Бу карарның көче 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибенә кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 24 апрель, 244 нче
карары редакциясендә)

**2017 елга Россия Федерациясе территориясеннән һәм (яки) территориясендә гамәлгә ашырыла торган һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүнең субсидия бирелә торган маршрутлары исемлеге**

| Т/с | Һава транспорты белән пассажирлар йөртү маршрутлары | | Атнага парлы рейслар ешлыгы | Елга парлы рейслар саны | Махсус тариф-ның чик зурлыгы, сум | Бер парлы рейска Татарстан Республикасы бюджетыннан авиапассажирлар йөртүчеләргә бирелә торган субсидия күләме, сум | Һавада йөртүләрне башкару чоры |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | шәһәр | шәһәр | | | | | |
| 1. | Казан | Пермь | 5 | 218 | 3 225,0 | 59 704,5 | 15.02.2017 – 31.12.2017 |
| 2. | Казан | Түбән Нов-город | 4 | 165 | 2 741,0 | 50 566,5 | 01.03.2017 – 31.12.2017 |
| 3. | Казан | Самара | 7 | 320 | 2 258,0 | 19 980,5 | 15.02.2017 – 31.12.2017 |
| 4. | Казан | Оренбург | 3 | 137 | 3 708,0 | 37 106,5 | 15.02.2017 – 31.12.2017 |
| 5. | Казан | Пенза | 5 | 225 | 2 741,0 | 16 108,0 | 20.02.2017 – 30.12.2017 |
| 6. | Түбән Кама | Түбән Нов-город | 3 | 135 | 3 708,0 | 23 267,0 | 20.02.2017 – 30.12.2017 |
| 7. | Түбән Кама | Самара | 3 | 120 | 2 258,0 | 19 980,5 | 27.03.2017 – 31.12.2017 |